СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**09.07.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 315**

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 15 мартындагы 135 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Э.Р. Кадникованың мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, 2007 елның 2 мартындагы"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 25-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 20 статьясы, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 15 мартындагы 135 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Нигезләмәнең 1нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Нигезләмә 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең

җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе һәм шартлары (алга таба - конкурс) билгеләнә.

Әлеге Нигезләмә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.»;

1.2.Нигезләмәнең 4 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 нче пунктча өстәргә:

«5) муниципаль хезмәтнең кече һәм өлкән вазыйфаларына билгеләгәндә.»;

1.3.10 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) «Россия Федерациясе Президентының «Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында»2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган форма буенча, конкурс уздыру елыннан алдагы календарь елда гражданның мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр,шулай ук конкурсны уздыру елына кадәрге календарь елда гражданның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль**
**районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**